Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районыТайсуган авыл җирлегенең
Тайсуган авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

28 ноябрь 2022 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2022 елның 26 ноябрендә 09сәгать 00 минутта, 2022 елның 26 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта,2022 елның 26 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта, 2022 елның 26 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге "Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлеге Тайсуган авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү, Әфганстан Республикасында һәм башка сугыш барган илләрдә интернациональ бурычларын үтәүчеләрдән, шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш (ата-аналарыннан, хатыны, балаларыннан) һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: Тайсуган елгасы аша җәяүлеләр күперен капиталь ремонтлау, Сәлахетдинов урамындагы тротуарны капиталь ремонтлау, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү?" соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 792 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 414 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 414 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлегенең Тайсуган авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлегеТайсуган авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү, Әфганстан Республикасында һәм башка сугыш барган илләрдә интернациональ бурычларын үтәүчеләрдән, шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш (ата-аналарыннан, хатыны, балаларыннан) һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: Тайсуган елгасы аша җәяүлеләр күперен капиталь ремонтлау, Сәлахетдинов урамындагы тротуарны капиталь ремонтлау, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләүгә ризамы?" турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Тайсуган авылы, Сәлахетдинов урамы, 36б йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә,«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында»

(PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Тайсуганавыл җирлеге башлыгы М.Ф.Мостафин